МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.04.2019 г. Казань № 346 ОД

Татарстан Республикасы мәдәният министрының 2017 елның 25 июлендәге 604-од номерлы боерыгы белән расланган Эш бирүче вәкиленең Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы мәдәният министрының “Эш бирүче вәкиленең Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турында” 2017 елның 25 июлендәге 604-од номерлы боерыгы белән расланган Эш бирүче вәкиленең Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында “бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы,” сүзләрен төшереп калдырырга;

Тәртипкә 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

**Министр** **И.Х. Аюпова**

Эш бирүче вәкиленең Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы мәдәният министрына

______________________________________

______________________________________

______________________________________

(Ф.И.А.и., биләгән вазыйфасы һәм структур бүлекчәсе,

______________________________________

яшәү урыны адресы,

______________________________________

телефон номеры)

Эш бирүче вәкиленнән Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренең коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт соравы турында
гариза

Миңа ______________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтенең исеме)

белән идарә итүдә_____________________________________________________.

(бердәнбер башкарма органның яисә коллегиаль идарә органының исеме)

буларак түләүсез катнашырга, коллегиаль идарә органы составына керергә (тиешлесенең астына сызарга) рөхсәт бирүегезне сорыйм.

___________ ________________ ___________________________

(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)